Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл Советы
КАРАРЫ

5 август 2022 ел

№ 44

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы 7.4 өлешен, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясы 4.3 өлеше, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» турындагы 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указының 8 пункты нигезендә

Миңлебай авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Миңлебай ав., Ш.Бикчурин ур., 50 йорт; Миңлебай ст., Шоссе ур., 20а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Миңлебай авыл җирлеге башлыгы И.М.Рәхимов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл
Советының 2022 елның 5
августындагы 44 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү

ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегендә биләүче затларга кагыла:

- муниципаль вазыйфа (депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат);

- муниципаль хезмәт вазыйфасы.

2. Әлеге Тәртип «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге сайтында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затларның (алга таба - вазыйфаи затлар), аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру процедурасын (алга таба - сайт) регламентлаштыра, шулай ук, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан белешмәләр урнаштыру тәртибе билгеләнмәгән булса, массакүләм мәгълүмат чараларына белешмәләр бирү өчен массакүләм мәгълүмат чараларына белешмәләр бирү процедурасын регламентлаштыра.

3. Сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен түбәндәге белешмәләр бирелә:

а) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында булган яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының һәркайсының урнашу төре, мәйданы һәм иле күрсәтелгән исемлеге;

б) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукындагы транспорт чаралары төре һәм маркалары күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюталар сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (килешү суммасы) хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына

кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып киткән булса, акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.

4. Сайтта урнаштырыла торган һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә торган белешмәләрдә түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, күрсәтелгән затларга милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка белешмәләр (әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрдән тыш);

б) ир яисә хатынның (иренең) яисә хатынының, балаларның һәм вазыйфаи зат гаиләсенең башка әгъзаларының шәхси күрсәткечләре;

в) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм аралашуның башка индивидуаль чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

г) вазыйфаи затка, аның хатынына (иренә), балаларына, гаиләнең башка әгъзаларына караган яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

д) дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүмат.

5. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, биләгән зат тарафыннан аның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр хезмәткәр үз вазыйфасын биләгән орган сайтында булган һәм аларны бирү срогы тәмамланган көннән алып ел саен 14 эш көне эчендә яңартыла торган керем, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте (алга таба - кадрлар хезмәте) белән тәэмин ителә.

7. Вазыйфаи зат төгәлләштерелгән белешмәләр тапшырганда тиешле үзгәрешләр төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көненнән дә соңга калмыйча сайтта урнаштырылган белешмәләргә кертелә.

8. Массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау килгәндә, кадрлар хезмәте:

а) запрос кергән көннән алып өч эш көне эчендә аның турында сорау кергән вазыйфаи затка хәбәр итә;

б) запрос кергән көннән алып җиде эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүне, әгәр соратыла торган белешмәләр сайтта булмаса, тәэмин итә.

9. Кадрлар хезмәтенең муниципаль хезмәткәрләре әлеге Тәртипне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә фаш иткән өчен җаваплы булалар.

Миңлебай авыл җирлеге башлыгы И.М.Рәхимов